# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **09. 11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Чубар-Абдул авыл җирлегенэ
керүче Чубар-Абдул авылында 2020 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү. 2
2. Бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү

- юлларга щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Чубар Абдул авылында Совет урамы, тыкрык - Совет урамынын 103 йортынан Чапаев урамынан 22 йортка кадәр, тыкрык Совет урамынын 115 нче йортынан Чапаев урамының 33 йортка кадәр:
Чубар-Абдул авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- Чубар-Абдул авылында урам исемнәре язылган табличкалар ясау;
- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгы: Н. Ә. Фәтхетдинов